ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКАРАЗЕРИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Старый Каразерик, ул.Советская,
д.12, , 423965

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Иске Каразирек авылы, Совет
урамы, 12 йорт, 423965

Тел.:(85593) 4-12-27, факс:4-12-27, e-mail: Skar.Utz @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 3** **11 март 2016 ел**

*2015 елның 7 октябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразерик авыл җирлеге территориясендә урнашкан, дәүләт милке чикләнмәгән муниципаль милекне һәм җир кишәрлекләрен сату буенча конкурс (аукцион) комиссиясе составын раслау турында»гы 24 санлы Иске Каразерик авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында*

2015 елның 26 декабрендәге «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы 109-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Юстиция министрлыгының Хокукый экспертиза нәтиҗәсен карап чыгып, Иске Каразерик авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2015 елның 7 октябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразерик авыл җирлеге территориясендә урнашкан, дәүләт милке чикләнмәгән муниципаль милекне һәм җир кишәрлекләрен сату буенча конкурс (аукцион) комиссиясе составын раслау турында" 24 санлы Иске Каразерик авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
1.1. Карарның 1, 2 пунктларыннан, атамасында һәм 1.1 пунктында «дәүләт милке чикләнмәгән» сүзтезмәсен алып ташларга;
1.2. Аерым затлар башка эшкә күчү сәбәпле, комиссия составынан чыгарырга: Ютазы муниципаль районы Финанс – бюджет палатасы Рәисе С.М. Мөхәммәтовны (килешү буенча), комиссия составына кертергә: Ютазы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Р.Г.Мөхәммәтованы (килешү буенча).
2. Әлеге карарны мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://jutaza.tatarstan.ru.и Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы** **Р.Р.Вәлиев**

Котловская Г.С.
4-12-27